ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.03.2023 Балык Бистәсе штп. №106пи

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә сайлау участоклары төзү турында» 2013 елның 18 гыйнварындагы 08пи номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы 2.1 пунктының "д" пунктчасына туры китереп КАРАР БИРӘМ:

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә сайлау участоклары төзү турында» 2013 елның 18 гыйнварындагы 08пи номерлы карары кушымтасына (Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 31 июлендәге №142пи, 2015 елның 4 августындагы №200пи, 2016 елның 24 июнендәге № 101пи, 2018 елның 10 апрелендәге №68пи, 2019 елның 28 июнендәге №205пи карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

16 нчы пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: "Участок № 2428. Үзәге - "Зур Мәшләк урта төп гомуми белем бирү мәктәбе" МБОУ, Зур Мәшләк авылы, Мәктәп урамы, 1а йорт, тел.3-33-68. Сайлау участогы чикләренә түбәндәге торак пунктлар керә: Зур Мәшләк авылы, Югары Мәшләк авылы."

39 нчы пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: "Участок № 2451. Үзәге- авыл клубы бинасы, Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авылы, Парк урамы, 10 йорт, тел.3-22-14. Сайлау участогы чикләренә түбәндәге торак пунктлар керә: Алан-Полян авылы, Кызыл-Йолдыз урман хуҗалыгы авылы».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифасын башкаручы А.А. Хәкимуллин